Иштуган авыл җирлеге составына керүче

Иштуган торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

16.09.2022 №1

2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән «2023нче елда Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлегенә караган Иштуган торак пунктында үзара салымны һәр балигъ булган кешедән 500 сумнан кертү турында килешәсезме» мәсьәләсе буенча 16.09.2022 елда гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 417 кеше кертелгән, 214 кеше тавыш бирүдә катнашкан. Җыенда катнашучылар саны - 51,32% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 214 кеше тавыш бирде;

**«Юк»** позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Иштуган авыл җирлеге составына кергән Иштуган авылында халык җыены булып узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2. “2023нче елда Саба муниципаль районының Иштуган авыл җирлегенә караган Иштуган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салымны 500 сум сумнан кертү турында”гы карарны танырга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:
   - Иштуган тимер юл разъезды поселогы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунт эшләү ,комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
   - Иштуган тимер юл разъезды поселогы чикләрендә вак таш белән капланган җирле әһәмияттәге юлларда чокырларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башлыгына җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче,
Иштуган авыл җирлеге башлыгы Д.М.Гайнутдинов